**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 1** **20 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче Карамалы-Елга авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 16 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2021 елда Түйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз)сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Карамалы-Елга авылы зиратында ритуаль йорт әзерләү һәм урнаштыру (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
- Карамалы-Елга авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар ( янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
- Карамалы-Елга авылында авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (тракторчыга механикалаштырылган кар җыештыру буенча хезмәтләр өчен түләү ,чит оешмаларның юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләре өчен түләү );
- Карамалы-Елга авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Авыл бәйрәме», нә бүләк, сувенир продукция сатып алу);
- Карамалы-Елга авылы урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү; (лампаларны ,яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру ,урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 46 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 29 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 29 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче Карамалы-Елга авылында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: « Сез, 2021 елда Түйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз)сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Карамалы-Елга авылы зиратында ритуаль йорт әзерләү һәм урнаштыру (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

- Карамалы-Елга авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар ( янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча хезмәт өчен түләү);

- Карамалы-Елга авылында авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (тракторчыга механикалаштырылган кар җыештыру буенча хезмәтләр өчен түләү ,чит оешмаларның юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләре өчен түләү );

- Карамалы-Елга авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Авыл бәйрәме», нә бүләк, сувенир продукция сатып алу);

- Карамалы-Елга авылы урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү; (лампаларны ,яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру ,урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.